Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил
№21-О, 03.09.2018
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
№ под-1307/18, 05.09.2018
Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы
№ 9, 31.08.2018
Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы
№ 92, 27.08.2018
«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр
буенча республика агентлыгы
№ 24-п, 28.08.2018

«Ребенок в мире прав» – «Бала хокук даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликларның республика конкурсы турында»гы боерыкка үзгәрешләр кертү хакында

«Ребенок в мире прав» – «Бала хокук даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликларның республика конкурсын үткәрү тәртибен төгәлләштерү һәм Республика конкурсының оештыру комитеты составын актуальләштерү максатларында, **боерабыз:**

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 02.09.2015 № 19, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының № под-9233/15, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының № 533, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының № 01-02/629, «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының № 30-П уртак боерыгына (Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 13.10.2016 № 37-о, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының № под-2097/16, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының № 2, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының № 01-02/269, «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгының № 32п боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. Күрсәтелгән боерык белән расланган «Ребенок в мире прав» – «Бала хокук даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликларның республика конкурсы турында»гы нигезләмәдә:

3.1 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

3.2 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Конкурста катнашуга дәгъва кылучы агымдагы елның 10 сентябреннән 20 октябренә кадәр (тулысынча кертеп) Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратына әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендә тутырылган заявканы, аңа өстәп, теләсә нинди электрон рәвештәге (CD- яисә DVD-диск, флеш-туплама һ.б.лар.) видеороликны җибәрә. Бер заявкага бер видеоролик өстәлергә мөмкин.

Видеоролик белән заявка түбәндәге адреска җибәрелә:

420015, Казан шәһәре, Карл Маркс урамы, 61 йорт (2 нче кат) яисә e-mail: rebenok-v-mire-prav@yandex.ru).

Түбәндәгеләр карауга алынмый:

әлеге пунктта күрсәтелгән сроктан соң җибәрелгән видеороликлар белән заявкалар;

видеороликсыз җибәрелгән заявка;

заявкасыз җибәрелгән видеоролик.»;

5.5 пунктта:

икенче абзацта «31 октябрьгә кадәр» сүзләрен «20 октябрьгә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «1 ноябрьдән» сүзләрен «21 октябрьдән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Күрсәтелгән боерык белән расланган «Ребенок в мире прав» – «Бала хокук даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликлар республика конкурсының оештыру комитеты составында:

оештыру комитеты составыннан Л.Ю. Глухованы; Р.М. Гарифуллинны төшереп калдырырга;

оештыру комитеты составына Татарстан Республикасы юстиция министры Заһидуллин Рөстәм Илдус улын, Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры Фәттахов Дамир Илдус улын кертергә.

Татарстан Республикасында
Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Г.Л. Удачина

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
Татарстан Республикасы мәгариф
һәм фән министры Р.Т. Борһанов

Татарстан Республикасы

яшьләр эшләре министры Д.И.Фәттахов

Татарстан Республикасы юстиция
министры Р.И. Заһидуллин

«Татмедиа» матбугат һәм
массакүләм коммуникацияләр
буенча республика агентлыгы
җитәкчесе А.Р. Зарипов